**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнары Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру, шулай ук мониторинг уздыруга вәкаләтле органның коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча башка дәүләт органнары белән мәгълүмати хезмәттәшлеген тәэмин итү буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә мониторинг оештыру һәм үткәрү чаралары турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 3 маендагы 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителү белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнары Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру, шулай ук мониторинг уздыруга вәкаләтле органның коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча башка дәүләт органнары белән мәгълүмати хезмәттәшлеген тәэмин итү буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелегенә мониторинг оештыру һәм үткәрү чаралары турында» 2011 елның 23 мартындагы ПУ-148 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 4 июнендәге ПУ-523 номерлы, 2018 елның 25 августындагы ПУ-586 номерлы, 2021 елның 12 апрелендәге ПУ-284 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 14 апрелендәге 234 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы тарафыннан» сүзләрен «республика башкарма хакимияте органы тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына» сүзләрен «Республика башкарма хакимияте органнарына» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 26 июль
№ 511